СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.04.2026 № 12-67

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең XXIII Гражданнар Җыенының 13.11.2017 ел № 3 карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру буенча таләпләрнең үз көчен югалтуын тануга бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 31.12.2025 ел № 1009 Указына таянып,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең XXIII Гражданнар җыенының 13.11.2017 ел № 3 карарының үз көчен югалтуын танырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес

буенча: http://verhniy-uslon.tatarstan.ru шулай ук Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Иннополис шәһәре Мэры вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы И.Р. Хуззятов